**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2023 елның «26» маеннан № 34-268

2022 елда «2021-2025 елларга Яңа Чишмә муниципаль районы мәгариф системасын үстерү» муниципаль комплекслы программасының «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә балалар сәламәтлеге, физик культура һәм спортны үстерү» ярдәмче программасын тормышка ашыру һәм 2023елга бурычлар

2022 елда «2021-2025 елларга Яңа Чишмә муниципаль районы мәгариф системасын үстерү» муниципаль комплекслы программасының «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә балалар сәламәтлеге, физик культура һәм спортны үстерү» ярдәмче программасын тормышка ашыру һәм 2023елга бурычлар турында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге башлыгы А.И.Бутинаның мәгълүматын тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елда «2021-2025 елларга Яңа Чишмә муниципаль районы мәгариф системасын үстерү» муниципаль комплекслы программасының «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә балалар сәламәтлеге, физик культура һәм спортны үстерү» ярдәмче программасын тормышка ашыру һәм 2023елга бурычлар турында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге башлыгы А.И.Бутинаның мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлегенә максатчан эш алып барырга:

- районның белем бирү оешмаларында сәламәтлекне саклау өчен шартлар тудыру һәм укучыларның, тәрбияләнүчеләрнең сәламәтлеген саклау өлешендә белем бирү учреждениеләренә карата Федераль таләпләрне үтәү буенча;
- балаларның сәламәтлеген саклау һәм физик үсеше өлкәсендә педагогларның методик белемнәрен күтәрү буенча;
- укучыларның хәрәкәт активлыгын арттыру буенча.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге:

- яңа уку елында «Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» МБУда балалар өчен волейбол секциясен оештырырга.

4. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлегенә Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге белән берлектә, эш алып барырга:

- спорт-сәламәтләндерү объектлары инфраструктурасын файдаланып, укучыларны физик культура һәм спорт белән актив шөгыльләнүгә җәлеп итү буенча;

- белем бирү учреждениеләрен спорт инвентаре һәм җиһазлар белән тәэмин итү буенча.

5. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы мәгариф учреждениеләренә эшне көчәйтергә:

- укучыларның физик компетенцияләрен: сәламәт яшәү рәвеше алып бару сәләтен үстерүдә;

- сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча лекцияләр оештыруда.

6. Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районы рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының социаль, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль
районы Башлыгы

В.М. Козлов